ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СРЕДНЕКОРСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Молодежная, д.13, д. Средняя Корса,
Арский муниципальный район, 422024

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРТА КУРСА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Яшьләр ур, 13 нче йорт, Урта Курса авылы,
Арча муниципаль районы, 422024

Тел. (84366) 53-4-32, факс (84366) 53-4-32. E-mail: Skor.Ars@tatar.ru

**Урта Курса авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**24 сентябрь 2018** **№27**

**Референдум уздыру буенча инициатива күрсәтү турында**

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Урта Курса авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Урта Курса авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Җирле референдум уздыруны түбәндәге сорау буенча тәкъдим итәргә:

"2019 елда Урта Курса авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 800 сум күләмендә (түләү күләме 400 сум тәшкил иткән укуның көндезге формасында укучы студентлардан, балачактан инвалидлардан, 90 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш,) үзара салым акчасы җыю һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү гә җибәрү белән килешәсезме?

| | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең аталышы | Планлаштырылган чаралар |
|---|---|---|
| 1 | Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге | - Сарай-Чокырча авылында юл-урам челтәренә нигез салу һәм вак таш җәю:<br>Г. Камал ур., 1дән 8гә кадәр, 14тән 16га кадәр;<br>М. Җәлил ур., 26 йорттан 28 йортка кадәр;<br>- Түбән Курса авылы:<br>Пушкин ур., 11 йорт янындагы тыкрык, Мәскәү ур., 29 йорт<br>- Югары Курса т. п. Школьная ур., 2 нче йорттан алып 42 нче йортка кадәр юл-урам челтәренең асфальт-бетон катламын урнаштыру. |
| 2 | Җирлек территориясен төзекләндерү | Югары Курса авылында агачларны санитар кисү |
| | | Урта Курса авылы, Югары Курса авылы, Түбән Курса авылы, Алан, Корайван, Сарай-Чокырча авылы урамнарнын яктырту челтәрләрен ремонтлау |

| | | |
|---|---|---|
| 3 | Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру | Корайван авылында су башнясын сатып алу һәм урнаштыру |
| 4 | Күмү урыннарын карап тоту | Урта Курса, Сарай-Чокырча авыллары зираты коймаларын ремонтлау һәм материаллар сатып алу |

Әйе юк

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм гражданнар күплэп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Урта Курса авылы, Яшьләр ур., 13, Урта Курса авылы, Тукай ур., 21.

Урта Курса авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Вафина

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СРЕДНЕКОРСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН 1609009731